ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«01»декабря 2020 ел № 126-р

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының
Яңа ел бәйрәмнәренә бәйрәм бизәлеше турында

Традицияләрне үстерү һәм аңа ярдәм итү, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының җәлеп итүчән йөзен формалаштыру, Яңа ел бәйрәмнәрендә район халкы һәм кунаклары өчен бәйрәм атмосферасы булдыру максатларында:

1. 2020 елның 20 декабреннән 27 декабренә кадәр «Кышкы әкият» район смотр-конкурсы турындагы Нигезләмәгә нигезендә «Кышкы әкият» район смотр-конкурсын үткәрергә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура, торак-коммуналь хуҗалык һәм шәһәр төзелеше бүлегенә предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләре белән биналарның һәм аның янәшәсендәге территорияләрнең фасадының яңа ел атрибутикасын бизәү буенча “Кышкы бизәкләр” номинациясе буенча эш оештырырга.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегенә шәхси эшмәкәрләр белән “Кышкы бизәкләр” номинациясе буенча эш оештырырга:

- сәүдә заллары интерьерларының Яңа ел атрибутикасы белән бизәү,
- сатучыларда яңа ел костюмнары булдыру,
- сәүдә, җәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләре биналарының һәм аның янындагы территорияләрнең фасадларын бизәү.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының авыл җирлекләре башкарма комитетларына авыл җирлекләре арасында «Кар патшасы патшалыгы» номинациясе буенча һәм шәхси сектор йортлары арасында «Яңа ел ишегалды» номинациясе буенча конкурс үткәрүне тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Әгерҗе шәһәре” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына Әгерҗе шәһәре урамнары арасында «Кар патшасы патшалыгы» номинациясе буенча һәм шәхси сектор йортлары арасында «Яңа ел ишегалды» номинациясе буенча конкурс үткәрүне тәкъдим итәргә.

6. «СПМ-184» идарәче компаниясенә «Карлы шәһәр» номинациясе буенча Әгерҗе шәһәренең күпфатирлы торак йортлары арасында конкурс уздыруны оештырырга тәкъдим итәргә.

7. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының МКУ “Мәгариф идарәсе”нә район мәгариф учреждениеләре арасында “Яңа ел әкиятендә кунакта” номинациясе буенча конкурс уздыруны оештырырга.

8. Милек рәвешләренә бәйсез рәвештә предприятие, оешма, учреждение җитәкчеләренә, шәхси эшмәкәрләргә тәкъдим итәргә:

8.1. Яңа ел атрибутикасы биналарын бәйрәм белән бизәгән өчен җаваплы затларны билгеләргә, янәшәдәге территорияне төзекләндерүгә һәм яктыртуга, табигый утыртмаларны һәм урнаштырылган чыршыларны якты бизәүгә аерым игътибар бирергә.

8.2. Түбәндәгеләр өчен җаваплы затларны билгеләргә:

- бәйрәм бизәлеше элементларын үз вакытында кабызу һәм сүндерү;
- бәйрәм бизәлеше элементларын эксплуатацияләү процессында барлыкка килә торган дефектларны демонтажлау яки бетерү;
- куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү.

9. Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәрен үткәрү чорында гражданнарның тормыш иминлеген, сәламәтлеген һәм мөлкәтен саклауны тәэмин итү максатларында, Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы Әгерҗе районы буенча бүлеге башлыгына, Россия Федерациясе Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең Әгерҗе районы буенча дәүләт янгын күзәтчелеге бүлеге башлыгына киңәш итәргә:

- кешеләр күпләп җыела торган урыннарда гадәттән тыш хәлләрне кисәтү чаралары комплексын гамәлгә ашырырга;
- күңел ачу характерындагы пиротехник әйберләрне кайтаруны һәм сатуны контрольдә тоту.

10. Конкурс уздыруга бәйле чараларны финанслау муниципаль бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

11. Әлеге күрсәтмәне “Әгерҗе хәбәрләре” район газетасында бастырып чыгарырга һәм районның рәсми сайтында agryz.tatarstan.ru урнаштырырга.

12. Күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең кураторлык юнәлешләре буенча урынбасарларына йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Башкарма
комитетының
01.12.2020 № 126-р
күрсәтмәсенә кушымта

**"Кышкы әкият" район смотр-конкурсы турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## I. Гомуми нигезләмәләр

“Кышкы әкият” район смотр-конкурсы (алга таба - смотр-конкурс) барлык милек рәвешләрендәге предприятиеләрне, учреждениеләрне, оешмаларны, район халкын Яңа ел бәйрәмнәрендә район халкы һәм кунаклары өчен бәйрәм атмосферасы булдыру максатында уздырыла.

## II. Конкурс бурычлары

2.1.Әгерҗе муниципаль районы территориясен кышкы чорда комплекслы төзекләндерү.
2.2.Район территориясен бизәүдә дизайнер карарларының яңа формаларына ярдәм итү һәм аларны үстерү.
2.3. Барлык милек рәвешләрендәге оешмалар, шәхси эшмәкәрләр һәм халыкның урамнарны, ишегалларны, якын-тирә территорияләрне, кибетләр витринасы, сәүдә павильоннарын яңа елча бизәү буенча активлашуы.
2.4 Район халкының һәм кунакларның ялын оештыру, балаларның һәм яшүсмерләрнең кышкы каникул көннәрендә ял итүен оештыру.

## III. Смотр-конкурсның максатлары

3.1.Яңа ел бәйрәмнәренә районның стандарт булмаган иҗади якын килүен стимуллаштыру.
3.2. Бәйрәм бизәлешенең сәнгати дәрәҗәсен күтәрү.
3.3.Район халкының күпләп ял итү урыннарын оештыру һәм бәйрәмчә бизәү.

## IV. Смотр-конкурста катнашучылар

4.1. Милекнең барлык рәвешләрендәге предприятиеләр, оешмалар, индивидуаль эшкуарлар.
4.2. Дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр.
4.3.Район халкы.

## V. Смотр-конкурсны үткәрү сроклары

Смотр-конкурс 2020 елның 20 декабреннән 27 декабренә кадәр үткәрелә.

## VI. Нәтиҗәләр ясау тәртибе

6.1. Смотр-конкурс нәтиҗәләре Әгерҗе муниципаль районы һәм шәһәре Советы, башкарма комитеты, “Мәгариф идарәсе” МКУ, Идарә компаниясе тарафыннан конкурсны уздыру өчен җаваплы итеп төзелгән конкурс комиссияләре тарафыннан 2020 елның 27 декабреннән дә соңга калмыйча игълан ителә.

6.2. Конкурс комиссияләре урынга чыгып, смотр-конкурс шартлары үтәлешен бәялиләр.

6.3. Конкурс комиссияләре карары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә һәм комиссия рәисе һәм барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

6.4. Смотр-конкурс нәтиҗәләре массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарыла.

## VII. Бүләкләү

7.1. Конкурс йомгаклары буенча һәр номинациядә катнашучылар Рәхмәт хатлары белән бүләкләнә.

"Кышкы бизәкләр" номинациясендә (бюджет учреждениеләре өчен):

"Карлы шәһәр" номинациясендә (күпфатирлы торак йортлар арасында):

"Яңа ел ишегалды" номинациясендә (шәхси йортлар арасында):

"Карлы патшалык" номинациясендә (кече бизнес объектлары өчен):

"Кар патшасы патшалыгы" номинациясендә (авыл җирлекләре арасында):

"Яңа ел әкиятендә кунакта" номинациясендә (предприятиеләр һәм оешмалар арасында):